# Конспект: “Мәңге яши, яшьни Тукай иҗаты”

**Максат:**

Г.Тукайның тормыш юлын һәм шигырьләрен өйрәнүне дәвам итү;

Сәнгатьле сөйләм күнекмәсен үстерү;

Г.Тукай иҗатына мәхәббәт тәрбияләү;

Рус һәм татар телен өйрәнүне дәвам итү.

Тәрбияче: Балалар, без бүген поездга утырып тукталышлар буйлап йөрибез! Әйдәгез әле, барыбыз да утырабыз, күзләрне йомабыз. Безнең поезд кузгала. Күзләрегезне йоммасагыз, ул урыныннан да кузгалмый.

Беренче тукталыш: “Татарча да яхшы бел, русча да яхшы бел” – дип атала.

(Поезд тавышы ишетелә, килеп җитәләр, экранда язу куела).

Экранда: “Татарча да яхшы бел,

Русча да яхшы бел.

Икесе дә безнең өчен,

Иң кадерле, татлы тел” – дип язылa.

(Шигырь юлларын укыйм).

– Без русча да, татарча да бик яхшы белергә тиеш. Хәзер рус теле дәресе булачак. Рус теле дәресендә без нинди телдә генә сөйләшергә тиеш?

– <u>Рус телендә.</u>

– Ә рус телендә ничек була?

<u>- (На русском языке. )</u>

– Как у вас настроение?

<u>- (Хорошее. )</u>

– Ребята, давайте сядем все красиво, спинки прямые, глазки смотрят на меня. Молодцы!

– Сегодня на улице тепло или холодно? Да, тепло. Какое сейчас время года?

- (Весна. )

(Төрле картиналар куела, шулар арасыннан яз картиналарын сайлап алырга кирәк була)

– А какие весенние месяцы вы знаете?

- (Март, апрель, май. )

– Мы на прошлом занятии познакомились с птицами. Давайте их вспомним и послушаем голоса.

(Презентация «Голоса птиц»).

– Это Скворец! Послушайте!

(Смотрим разных птиц и слушаем: ласточка, лебедь, соловей, жаворонок, журавль, кукушка).

– Как одним словом мы называем этих птиц?

- (Перелетные. )

– Молодцы! Вы знаете какой известный писатель родился весной и именно сегодня.

- (Да, Габдулла Тукай!)

– Правильно! Давайте посмотрим про него на экране.

(Презентация: “Габдулла Тукай”).

1 слайд: – Ребята, это кто?

- (Габдулла Тукай!)

2 слайд: – А это его мама и папа!

3 слайд: – Балалар кечкенә чагында Тукайны “Кечкенә Апуш” дип йөрткәннәр. Менә ул!

4 слайд: – Деревня где родился наш писатель: Кушлавыч!

5 слайд: – Все люди временами меняются, смотрите как изменился со временем Габдулла Тукай.

6 слайд: – Вот это картина вам знакома. Где он лежит?

- (В больнице. )

7 слайд: А это какая картина?

- (Здесь похоронен Габдулла Тукай. )

– Правильно.

8 слайд: Мы знаем очень много стихов и сказок нашего любимого писателя. Посмотрите на эти картинки. Из какого они стихотворения?

- (“Гали белән Кәҗә”. )

– Молодцы!

9 слайд: А это из какой сказки?

- (“Кәҗә белән сарык әкияте”. )

– Правильно.

– Расскажите, еще какие сказки и стихотворения вы знаете? (Ответы детей)

– Балалар, әйдәгез, Габдулла Тукайның үзебез белгән шигырьләрен сөйлибез.

(Балалар ятлаган шигырьләрен сөйлиләр).

– Балалар, без хәзер сезнең белән икенче тукталышка китәбез. Күзләрне йомабыз, матур итеп утырабыз. Киттек.

Икенче тукталыш: “Рәсем шөгыле тукталышы”.

– Менә килеп тә җиттек. Иң беренче эшне экраннан башлыйк. Мультфильм карыйк.

(Презентация : “Эш беткәч уйнарга ярый”).

– Балалар, сез әле генә Габдулла Тукайның нинди шигыренә мультфильм карадыгыз?

- (“Эш беткәч уйнарга ярый”. )

– Бик дөрес. Балалар, карагыз әле, бу мультфильмда нинди матур алмагач бар. Аның алмалары нинди төстә, балалар?

- (Кызыл).

– Сез бу мультфильмны караганда матур алмагач күрдегезме?

- (Әйе , күрдек).

– Әйдәгез әле, шул матур, кызыл алманы рәсемгә төшерик.

(Балалар рәсем ясыйлар).

– Бик матур булган бу. Балалар , бирегез миңа рәсемнәрегезне. Ә без тукталышлар буйлап йөрүебезне дәвам итәбез.

Өченче тукталыш: “Кул эше тукталышы”. Әйдәгез, матур итеп утырабыз, күзләрне йомабыз.

(Тактада агач кәүсәсе ясалган, мин балаларның алмаларын шунда тезеп куям).

– Балалар , карагыз әле, алмагач сезнең матур алмаларны үзенә алган. Ләкин ни өчендер бер алма кызармыйча яшел булып калган. Ни өчен?

- (Чөнки кояш җитми)

(Физкультминутка «Болыт чыкты»)

– Әйдәгез әле, бергәләшеп кояш ябыштырып куйыйк.

(Коллектив белән кояш ябыштырабыз, һәм алмагач янына элеп куябыз).

– Без алмагачка яңгыр да яудырдык, кояш та яктырттык, безнең алмагачыбыз сөенеп китте. Һәм шул сөенечтән сезгә алмаларын бирде, әйдәгез әле, алмаларны ашыйбыз.

– Балалар, сезгә бүген шөгыль ошадымы? (Балалар җавабы)

– Без бүген кем турында сөйләштек? (Балалар җавабы)

– Нәрсәләр карадык? (Балалар җавабы)

– Сез дә миңа бүген шөгыль вакытында үз-үзегезне тотышыгыз белән бик ошадыгыз. Рәхмәт сезгә бик зур!